СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет урамы, 7 нче йорт, Шиланга авылы,
422577

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

03.04.2024 ел | с. Шеланга | № 37-212

«Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенының 28.10.2023 ел № 12 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында.»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 12 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 13 апреленә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авылы җирлеге Шилангы авылы территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү

системаларын проектлау, ремонтлау (3 данә коены урнаштырып, 300 м озынлыктагы суүткәргеч төзү)

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Йорт яны территориясендә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Шилангы авылы, Совет урамы, 7 йорт, 11.20 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров